| | |
|---|---|
| **СОВЕТ КУЛАНГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕСОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 12 нче декабре Колаңгы станциясе №31

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең 2020 елга, 2021 һәм 2022 елларның план чорына бюджеты проекты хакында

**1 нче статья**

1.2020 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджетының фаразланган гомуми керем күләме сумме **1606,6**мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме **1606,6**мең сум тәшкил итә.

3) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджеты кытлыгының иң чик күләме 0,00 мең сум күләмендә.

2. 2021 һәм 2022 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджетының фаразланган гомуми керем күләме:

- 2021 елның план чорына 1622,0 мең сум күләмендә
- 2022 елның план чорына 1665,4мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме:

- 2021 елның план чорына 1622,0 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар – 38,3мең сум күләмендә;
- 2022 елның план чорына 1665,4 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар – 79,0 мең сум күләмендә;

3) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең 2020 нче елның план чорына бюджет дефициты 0,00 мең сум күләмендә һәм 2021 нче елның план чорына 0,00 мең сум күләмендә.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын раслау турында:

- 2020 елга әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә;

- 2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге карарның2 нче кушымтасы нигезендә;

**2 нче статья**

1.2021 елның 1 гыйнварына эчке бурычның югары чиге 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге нуленче мәгънәгә ия дип билгеләргә.

2. 2022 елның 1 гыйнварына эчке бурычның югары чиге 0,00 мең сум, шул исәптән Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге нуленче мәгънәгә ия дип билгеләргә.

3. 2023 елның 1 гыйнварына эчке бурычның югары чиге 0,00 мең сум, шул исәптән Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге нуленче мәгънәгә ия дип билгеләргә.

**3нче статья**

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге бюджетында 2020 елга фаразланган керемнәрнең күләмен әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә, 2021 һәм 2022 нче елларның план чорына, әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

**4 нче статья**

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганагының баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә расларга.

**5нче статья**

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

- 2020 елга әлеге карарның 7 нче кушымтасы нигезендә;

- 2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге карарның 8 нче кушымтасы нигезендә.

2. Бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре,бүлекчәләре, максатчан статьялары чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне расларга:

- 2020 елга әлеге карарның 9 нче кушымтасы нигезендә;

- 2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге карарның 10 нче кушымтасы нигезендә.

3. Бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчанстатьялары  чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне расларга:

- 2020 елга әлеге карарның 11 нче кушымтасы нигезендә;

- 2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге карарның 12 нче кушымтасы нигезендә.

4. 2020-2022 елларга гаммәви норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдергән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен ел саен 0,00 мең сум итеп расларга.

**6 статья**

Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге бюджетында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен исәпкә алырга.

- 2020 елда 570,1 мең сум күләмендә,

- 2021 елның планлы периодында 572,4 мең сум, 2022 елда 601,2 мең сум күләмендә.

**7 нче статья**

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы  авыл җирлеге бюджетында 2020 елда хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетыннан субвенцияләрнең күләмен 2021 елда 92,0 мең сум күләмендә, 2022 елда 93,0мең сум күләмендә исәпкә алырга.

**8 нче статья**

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында»гы 2011 елның 07 декабрендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законны законны үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге бюджетында, төзелгән килешүләр нигезендә, тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруга Кайбыч муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен күз алдында тотарга.:

- 2020 елда 18,0 мең сум күләмендә,

- 2021 елның план чорында 18,0 мең сум һәм 2022 елда 18,0 мең сум күләмендә.

**9 нчы статья**

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы  авыл җирлеге башкарма Комитеты 2020 елда муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук

муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең штат санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

**10 нчы статья**

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджетын үтәгәндә әлеге карар белән расланган керемнәрнең гомуми күләменнән фактта алынган керемнәр, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә, муниципаль бурыч алулар урынына, муниципаль бурычны түләүгә, шулай ук гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләре җитәрлек булмаган очракта, билгеләнгән тәртиптә җибәрелә, Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 217 статьясындагы 3 пунктында каралган.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджетын үтәгәндә әлеге карар белән расланган керемнәрдән тыш фактта алынган субсидияләр, субвенцияләр һәм бюджетара трансфертлар, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә генә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертеп, субсидияләр, субвенцияләр һәм бюджетара трансфертлар бирү максатларына чыгымнарны арттыруга җибәрелә.

**11 нче статья**

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджеты акчаларының Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге исеменнән 2019 елда шушы муниципаль контрактлар нигезендә түләнергә тиешле товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар төзелгән, файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә 2020 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**12 нче статья**

2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге милкендәге мөлкәтне арендага тапшырудан алынган һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының бюджет мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә оператив идарәгә тапшырылган керемнәрне бюджет керемнәре составына кертелә һәм әлеге карар нигезендә бюджет йөкләмәләрен үтәү өчен файдаланыла дип билгеләргә.

**13 нче статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджетның касса үтәлеше

буенча аерым функцияләрне һәм бюджеты үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү буенча төзелгән килешүләр нигезендә аерым функцияләрне башкара.

**14 нче статья**

Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**15 нче статья**

Әлеге карарны Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге территориясендә урнаштырылган махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга : http://kulanga-kaybici.tatarstan.ru.

**16 нчы статья**

Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Колаңгы авыл җирлеге Башлыгы Ф.Т.Нигматзянов